**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГОРАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423959, Республика Татарстан,
Ютазинский район, деревня Малые Уруссу,
улица Советская, дом 21А
тел. 85593 4-23-10, факс 85593 4-23-40

423959, Татарстан Республикасы,
Ютазы Районы, Кече Урыссу авылы,
Совет урамы, 21А йорты.
эл.адрес Tash.Utz@ tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31января 2023года №1

2017 елның 8 сентябрендәге "Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге муниципаль милкендәге автомобиль юлларына идентификацион номерлар бирү тәртибен раслау турында"гы 17 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2007 елның 8 ноябрендәге «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 257-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2007 елның 7 февралендәге 16 санлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитет к а р а р б и р ә:

1. 2017 елның 8 сентябрендәге «Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең муниципаль милкендәге автомобиль юлларына идентификацион номерлар бирү тәртибен раслау турында»гы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетының 17 санлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертеп, 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.
2. 2017 елның 8 сентябрендәге «Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең муниципаль милкендәге автомобиль юлларына идентификацион номерлар бирү тәртибен раслау турында»гы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетының 17 санлы карарының 2 нче кушымтасы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Ютазы муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р. К. Вәлиев